**Конституция турында төп нигезләмәләр**

Конституция – җәмгыять һәм дәүләт төзелешенең төп принципларын ачыклый, дәүләт хакимияте субъекты һәм аны гамәлгә ашыру механизмын билгели торган, дәүләт тарафыннан саклануча граждан җәмгыяте, кеше һәм граждан хокуклары ныгытыла торган бердәм, махсус юридик үзенчәлекләргә ия булган хокукый акт.

Хәзерге демократик дәүләтнең хокукый системасында мөстәкыйль һәм махсус әһәмияткә ия хокукый акт буларак. Конституция башка хокукый актлардан асылда аерылып тора. Шуның иң мөһиме – конституцияне билгеләүче төп субъект яисә аның кем исеменнән кабул ителүе. Конституция әлеге төшенчәнең хәзерге мәгънәсендә халык тарафыннан һәм халык исеменнән кабул ителә торган акт.

Конституция кабул итүче субъектның үзенчәлеге әлеге төшенчәнең икенче сыйфатына – аны гамәлгә куюга, конституциячел билгеләмәләрнең башлангыч характерына бәйле. Демократик дәүләттә халык – суверенитетның хуҗасы: хакимиятнең бердәнбер чыганагы булып торганга күрә, нәкъ менә ул гамәлгә куючы хакимият буларак, аның иң зур чагылышы да. Һәм менә нәкъ аңа конституцияне кабул итү, аның ярдәмендә җәмгыять һәм дәүләт төзелешенең нигезләрен билгеләү хокукы бирелә. Бары тик гамәлгә куючы хакимият кенә җәмгыять һәм дәүләт төзелеше нигезләрен үзгәртә, шул исәптән тамырдан үзгәртә ала.

Конституция төшенчәсен тасвирлаучы тагын бер мөһим сыйфат, конституциячел җайга салу мәсьәләсе, ягъни җәмгыятьнең җайга сала һәм ныгыта торган мөнәсәбәтләр катламы үзенчәлеге. Конституциячел йогынты даирәсе башка хокукый актларга караганда киң. Ул җәмгыятьнең барлык өлкәләренә: сәяси, икътисадый, социаль, рухи һәм башка өлкәләренә кагыла, бу өлкәләрдә җәмгыятьтәге төп, фундаменталь нигезләрне җайга сала.

Конституция аерым юридик сыйфатларга да ия. Алар түбәндәгеләр:

конституциянең өстенлеге;

югары юридик көче;

конституциянең аеруча саклануы;

конституцияне кабул итүнең һәм яңадан карауның, аңа төзәтмәләр кертүнең аерым тәртибе.

**Татарстан Республикасы Конституциясен әзерләү һәм кабул итү**

90 нчы еллар башында сәяси вакыйгаларның үсеше һәм Татарстан Республикасының статусын үзгәртү республиканың яңа Төп Законын эшләүгә тарихи зарурлыкны билгеләде.

90 нчы елның 24 августында Казанда “Татар Совет Социалистик Республикасы дәүләт суверенитеты турында” ТССР Декларациясен кабул итү таләбе белән күпсандагы халык катнашында митинг булды. 1990 нчы елның августында Югары Совет әлеге хокукый актны кабул итте. Документ шул чактагы СССРда яңа федератив мөнәсәбәтләр булдыру, аны күпмилләтле дәүләт буларак ныгыту, федераль һәм җирле хакимият органнарын үзгәртү, үзәкнең һәм төбәкләрнең мәнфәгатьләр нисбәтен билгеләү, республиканың үзбилгеләнешенә хокукын гамәлгә ашыру, сәяси һәм социаль-икътисадый мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итү кирәклегеннән чыгып төзелде.

Татарстан ССР Югары Советының 1990 елның 31 августындагы 337-XII номерлы карары белән Татарстан ССР Конституциясенә (Төп Законга) үзгәрешләр һәм өстәмәләр әзерләү буенча конституциячел комиссия төзелде.

СССР таркалганнан соң яңа Россия шартларында, Декларациягә салынган нигезләрне акрынлап тормышка ашырып, халык фикеренә таянып, республика Югары Советы 1992 елның 6 ноябрендә Татарстанның яңа Конституциясен кабул итте. Анда күпмилләтле демократик дәүләт төзүнең заманча идеяләре һәм принциплары чагылыш тапты.

1992 елның 6 ноябре Татарстан Республикасы өчен чын мәгънәсендә тарихи көн булды. Дәүләт суверенитеты турында Декларация һәм 1992 елның 21 мартында халык тавыш бирүе (референдум) йомгаклары нигезендә республика үсеше өчен киң мөмкинлекләр ачылды. Шуны билгеләп үтәргә кирәк, референдумны әзерләү һәм үткәрү “Татарстан Республикасы дәүләт статусы турында”гы мәсьәлә буенча республика референдумын үткәрү хакында” Татарстан Республикасы Югары Советының 1992 елның 21 февралендәге

карары нигезендә алып барылды. Референдум үткәрү буенча үзәк комиссия белешмәләреннән күренгәнчә, референдум бюллетенендә куелган: “Татарстан Республикасы – үз мөнәсәбәтләрен Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән тигез хокуклы шартнамәләр нигезендә коручы суверен дәүләт - халыкара хокук субъекты булу белән сез килешәсезме?” дигән сорауга тавыш бирүдә катнашкан барлык Татарстан Республикасы гражданнарының гомуми санынннан 61,4 проценты “әйе” дип җавап бирде. Бу республикада барлык яшәүче, референдумда катнашу хокукына ия халыкның 50,3 процентын тәшкил итте.

Яңа хокукый акт проекты буенча Татарстан Республикасының конституция комиссиясе ике елдан артык эшләде. Эш барышында чит илләрнең конституциячел төзелеш фәне һәм практикасы буенча материаллар җентекләп өйрәнелде. Конституция проекты буенча фикер алышу йомгаклары барышында кергән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр исәпкә алынды. Проект республика Югары Советы, халык депутатларының шәһәр һәм район советлары сессияләрендә, хезмәт коллективларында, җәмәгать оешмаларында, массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртылды һәм алар буенча фикер алышынды.

Конституция проекты халыкара хокукый экспертизаны уңышлы узды, аның халыкара демократик стандартларга туры килүе расланды.

1992 елның 6 ноябрендә республика тарихында беренче тапкыр өр яңа Төп Закон кабул ителде. Мондый Закон кеше хокукларын һәм ирекләрен төп хәзинә дип таныды, демократик тәртип нигезләрен билгеләде һәм дәүләткә әлеге нигези кыйммәтләрне саклау һәм яклау бурычын йөкләде.

Татарстан Республикасы Конституциясе кабул ителгән 1992 елның 6 ноябреннән алып әлегә кадәр Конституциягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында 16 закон кабул ителде. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, 1992 елгы Конституция илебездә демократик дәүләтчелек институтлары барлыкка килмәгән чорда, тулы канлы сәяси партияләр булмаганда, иҗтимагый үсеш идеологиясе, республика статусының билгесезлеге һәм Россия федерализм системасында аның урыны билгеләнмәгән шартларда кабул ителде. Шуңа күрә кайбер җитди җитешсезлекләрнең булуы әлеге документ өчен котылгысыз булып калды. Мәсәлән, анда кеше һәм гражданга бирелә торган төп хокукларның һәм ирекләрнең, шулай ук аларның гарантияләре

тулысынча һәм төгәл ачыкланмаган. Элеккеге, искечә күзаллауларның эзләре советлар, җирле үзидарә, халык депутаты статусы системаларын җайга салуда үз эзен саклап калган. Хакимият бүленеше принцибы декларатив рәвештә генә, аны аңлатуда башбаштаклыкка шактый урын калдырган.

Республика Конституциясенең җитешсезлекләре турында әйткәндә бер факторны истә тотарга кирәк, ул Россия Федерациясе Конституциясеннән иртәрәк кабул ителде. Шуңа күрә анда федераль конституциянең күп кенә нигезләмәләре исәпкә алынмаган. Шуңа күрә Конституциягә төзәтмәләр кертелде, шул исәптән шактый җитди төзәтмәләр. Моннан тыш, “Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителеп, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары системасын билгеләде, бу шулай ук республика Конституциясенә үзгәрешләр кертелүгә нигез булды.

Татарстан Республикасы Конституциясен Россия Федерациясе Конституциясе нигезләмәләренә туры китерүгә бәйле рәвештә килештерү комиссиясе төзелде, ул бер елга якын Төп Законның яңа редакциясе буенча эш алып барылды.

2022 елның апрелендә “Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” 1380 номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде, анда Татарстан Республикасы Конституциясе яңа редакциядә бәян ителде.

1992 елдан алып 2002 елга кадәр Татарстан Республикасы Конституциясенә 9 үзгәреш кертелде, ә аны яңа редакциядә раслаганнан соң, 2002 елның 19 апреленнән алып хәзергә кадәр 6 үзгәреш кертелде.

## Татарстан Республикасы Конституциясе структурасы

Татарстан Республикасы Конституциясенең структурасы һәм эчтәлеге Россия Федерациясе Конституциясе структурасына нигезләнә. Россия Федерациясе Конституциясенең 5 статьясы нигезендә республика (дәүләт) үз Конституциясенә һәм законнарына ия була.

Татарстан Республикасы Конституциясе преамбуладан һәм 7 кисәктән тора.

I КИСӘК. **КОНСТИТУЦИЯЧЕЛ КОРЫЛЫШ НИГЕЗЛӘРЕ**

II КИСӘК. **КЕШЕ ҺӘМ ГРАЖДАННЫҢ ТӨП ХОКУКЛАРЫ, ИРЕКЛӘРЕ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ**

**III КИСӘК. АДМИНИСТРАТИВ-ТЕРРИТОРИАЛЬ ТӨЗЕЛЕШ**

**IV КИСӘК. ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ ОЕШТЫРУ. БУ КИСӘК ДҮРТ БҮЛЕКТӘН ТОРА.**

**1 БҮЛЕК. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ**

**2 БҮЛЕК. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ.**

**3 БҮЛЕК. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**4 БҮЛЕК. СУД ХАКИМИЯТЕ. ПРОКУРАТУРА.**

**5 КИСӘК. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ**

**6 КИСӘК. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ СИМВОЛЛАРЫ ҺӘМ БАШКАЛАСЫ.**

**7 КИСӘК. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕН КАБУЛ ИТҮ ҺӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕНӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТӘРТИБЕ.**

Конституциячел төзелеш нигезләре төшенчәсенә дәүләтнең конституция белән беркетелгән характеристикасы керә. Татарстан Республикасы Конституциясенең 1 статьясында түбәндәгеләр билгеләнә: Татарстан Республикасы – Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсе нигезендә Россия Федерациясе белән берләшкән һәм Россия Федерациясе субъекты булган демократик хокукый дәүләт. Татарстан Республикасы суверенитеты, Россия Федерациясе карамагындагы мәсьәләләрдән һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе вәкаләтләреннән тыш, дәүләт хакимиятенең (закон чыгару, башкарма һәм суд) бөтен тулылыгына ия булуда чагыла һәм Татарстан Республикасының аерылгысыз хасияте була. Татарстан Республикасы һәм Татарстан исемнәре бер үк мәгънәгә ия. Татарстан Республикасы статусы Татарстан Республикасының һәм Россия

Федерациясенең үзара ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый. Татарстан Республикасы чикләре аның ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый. Татарстан Республикасы үз вәкаләтләре чикләрендә халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларда мөстәкыйль катнаша. Шуны билгеләп үтәргә кирәк, Төп Законның 1 статьясындагы нигезләмәләр республика Конституциясенең 123 статьясы нигезендә бары тик референдум нәтиҗәләре буенча гына үзгәртелергә мөмкин.

Конституциясенең 13 статьясы Татарстан Республикасын социаль дәүләт буларак, ә 11 статьясы дөньяви дәүләт буларак билгели.

Татарстан Республикасы демократик дәүләт дип билгеләнә. Әлеге төшенчә демократик дәүләт нигезендә дәүләтнең бурычларын һәм эшчәнлеген халык мәнфәгатьләреннән чыгып билгеләүне, дәүләт функцияләрен хәбәрдар гамәлгә ашыруны, гражданнарның сәяси һәм шәхси иреген, сәяси режимның гуманистик юнәлешен һәм башбаштаклыкка юл куймауны аңлата.

Татарстан Республикасын хокукый дәүләт буларак игълан итеп, конституциячел төзелеш нигезләренә Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Республикасы хокукый системасында югары юридик көче турындагы нигезләмәләр һәм аның республиканың бөтен территориясендә турыдан-туры гамәлдә булуы; Татарстан Республикасы Конституциясе – республиканың Төп законы, Татарстан Республикасының хокукый системасында иң югары юридик көчкә ия, турыдан-туры гамәлдә булуы һәм Татарстан Республикасының барлык территориясендә кулланылуы турындагы нигезләмәләр кертелә. Татарстан Республикасы законнары һәм башка хокукый актлары, шулай ук җирле үзидарә органнарының хокукый актлары Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килмәскә тиеш. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, оешмалар, учреждениеләр, вазыйфаи затлар һәм гражданнар Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш. Татарстан Республикасы законнары рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш. Басылып чыкмаган законнар кулланылмый. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы теләсә кайсы норматив хокукый акт, гомуми танышу өчен рәсми рәвештә басылып чыкмаган булса, кулланыла алмый (24 статья).

Татарстан Республикасы – сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт. (Татарстан Республикасы Конституциясенең 13 статьясы).

Республиканы дөньяви дәүләт буларак билгеләү бернинди идеология дә дәүләтнеке яисә мәҗбүри буларак билгеләнә алмауны аңлата. Дәүләткә мондый характеристика биреп, аны түбәндәге нигезләмәләрдә ача:

1. Бернинди дин дә дәүләт дине буларак яисә мәҗбүри буларак билгеләнә алмый.

2. Дини берләшмәләр дәүләттән һәм законнан аерылган.

Татарстан Республикасында суверенитетка ия булучы һәм хакимиятнең бердәнбер чыганагы – аның күпмилләтле халкы. (3 статья). Халык хакимияте принцибы, беренчедән, хакимиятнең бөтен тулылыгы белән халыкка каравын, икенчедән, халык үз хакимиятен турыдан-туры, шулай ук дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары аша гамәлгә ашыра дигәнне аңлата.

Кеше, аның хокуклары һәм ирекләре – иң зур хәзинә. Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау – Татарстан Республикасының бурычы. (2 статья). Конституциячел төзелешнең бу принцибын чагылдырып, республика 1948 елның 10 декабрендә БМО Генераль Ассамблеясе тарафыннан кабул ителгән һәм кеше гаиләсенең барлык әгъзаларына хас абруена, аларның бертигез һәм аерылгысыз хокукларын төп ирек, гаделлек һәм тынычлык дип тануны игълан итә торган Кеше хокукларының гомуми декларациясендә чагылдырылган халыкара тәҗрибәне һәм цивилизация максатларын исәпкә ала.

Конституциячел төзелеш һәм җәмгыять безнең илдә идеологик күптөрлелеккә һәм сәяси плюрализмга нигезләнә.

Һәм, ниһаять, конституциячел төзелеш сыйфатларының тагын берсе хуҗалык эшчәнлеге ирегеннән һәм милек рәвешләренең төрлелегеннән гыйбарәт. Татарстан Республикасында хосусый, дәүләти, муниципаль милек һәм милекнең башка рәвешләре таныла һәм бертигез рәвештә яклана.

Татарстан Республикасы Төп Законының үзенчәлеге - Татарстан Республикасы Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларга милли мәдәниятне, телне үстерүдә, аларның үзенчәлекләрен саклап калуда ярдәм күрсәтү (14 статья).

Татарстан Республикасы Конституциясенең тагын бер үзенчәлеге – анда Татарстан Республикасының дәүләтләр һәм халыклар арасындагы бәхәсләрне хәл итү чарасы буларак көч куллану һәм сугышны кире кагу турындагы нигезләмә булу. Республикада сугышны пропагандалау тыела.

Татарстан Республикасы Конституциясе дөнья җәмәгатьчелеге кыйммәтләрен һәм республикабызның шәхес, кеше һәм граждан хокукларына һәм ирекләренә якын килү эволюциясен чагылдыра. Шәхеснең, аның хокукларының һәм ирекләренең өстенлеге Татарстан Республикасы конституциячел төзелеш нигезләренең берсен тәшкил итә. Конституциядә ике кисәкнең исеме “Кеше һәм

гражданның төп хокуклары һәм ирекләре” дип аталу закончалыкка туры килә. Шәхеснең конституциячел статусын нигез итеп беркетү – аның иреге, туганнан алып төп хокукларга һәм ирекләргә ия булуы, аларның юкка чыкмавы, республикада шәхес статусының дөнья җәмәгатьчелегендә барлыкка килгән таләпләргә һәм стандартларга туры килүе, шәхеснең индивидуаль мәнфәгатьләренең башка затлар, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләре белән үрелеп баруы, төп хокукларның, ирекләрнең һәм бурычларның гомумилеге, юридик тигезлек, ягъни гражданнарның тигез хокуклылыгы, шәхеснең аның хокукларының һәм ирекләренең конституциячел статусы гарантияләнгән булу.

Конституциянең 28 статьясында тигез хокуклылык принцибы (һәркемнең хокук һәм суд алдында тигезлеге) беркетелә. Дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, нинди расадан һәм милләттән булуына, җенесенә, белеменә, теленә, сәяси карашларына, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, шөгыленең төренә һәм характерына, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли. Тигез хокуклылыкның өченче мәгънәсе 28 статьяның өченче өлешендә ачыла, аның буенча ир-ат һәм хатын-кыз тигез хокукларга һәм ирекләргә, аларны гамәлгә ашыру өчен тигез мөмкинлекләргә ия.

Татарстан Республикасы Конституциясе дөнья практикасында мәгълүм булган барлык хокукларны һәм ирекләрне беркетә. Бу өлкәдә Татарстан Республикасы Конституциясе кайбер хокукый нигезләмәләрне үз эченә ала, мәсәлән, дәүләт балигъ булмаганнарның, инвалидларның, социаль яклауга мохтаҗ һәм эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче бүтән гражданнарның хезмәт хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар булдыра, законда каралган очракларда аларны укытуны һәм аларның яңа квалификация алуларын оештыра. (50 статьяның 6 өлеше). Моннан тыш, Татарстан Республикасында конституциячел дәрәҗәдә дәүләтнең экологик иминлекне һәм табигатьтән рациональ файдалануны тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм сәламәтләндерү буенча чаралар күрү бурычы беркетелә (53 статьяның 2 өлеше).

Татарстан Республикасы Конституциясенең 30 статьясы нигезендә гражданнар шәхси, сәяси, социаль-икътисадый һәм мәдәни хокукларның һәм ирекләрнең бөтен тулылыгына ия. Шуңа бәйле рәвештә, республиканың Төп Законында кеше яшәргә; ирекле күчеп йөрергә, яшәү һәм тору урынын сайлап алуга; вөҗдан ирегенә, дин тоту ирегенә хокуклы дигән нигезләмәләр урын ала. Һәркем хосусый тормышының кагылгысызлыгына, шәхси һәм гаилә серенә, үзенең намусын һәм абруйлы исемен яклауга хокуклы. (36 статьяның 1 өлеше), шулай ук Һәркем хат язышу, телефон аша сөйләшүләр, почта, телеграф аша һәм башка төрле хәбәрләшүләр яшеренлегенә

хокуклы. Бу хокукны чикләү бары тик суд карары нигезендә генә рөхсәт ителә. (36 статьяның 2 өлеше). Әлеге статьяда күрсәтелгән хокукны чикләү бары тик суд карары нигезендә генә рөхсәт ителү турындагы нигезләмә зур яңалык булып тора. Төп Закон кабул ителгәнчегә кадәр бу хокук “компетентлы органнар” тарафыннан хәл ителгән. Иң яхшы очракта да прокурор санкциясен алу мәҗбүри булган. Һәркем үзенең милләтен билгеләргә һәм күрсәтергә хокуклы булуы республика өчен аеруча актуаль. (34 статья). Торакка хокук республика Конституциясенең үзенчәлеге булып тора. Конституциянең 55 статьясы нигезендә һәркем торакка хокуклы. Беркем дә торагыннан нигезсез рәвештә мәхрүм ителә алмый. Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар.

Конституция шулай ук һәркемнең туган теленнән файдалану, аралашу, тәрбия, уку һәм иҗат итү телен ирекле сайлап алу хокукына ия булуны беркетте.

Конституциядә Татарстан Республикасында гражданнар сәяси тормышта, дәүләт һәм җәмәгать эшләре белән идарә итүдә турыдан-туры да, үз вәкилләре аша да катнашырга, дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына сайларга һәм сайланырга, шулай ук референдумда катнашырга, Татарстан Республикасында һәркем дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына шәхсән мөрәҗәгать итәргә, шулай ук индивидуаль һәм күмәк мөрәҗәгатьләр җибәрергә хокуклы дип билгеләнә. Базар мөнәсәбәтләре нигезе буларак Конституция эшкуарлык эшчәнлеген алып бару хокукын беркетә, кеше аның өчен үз сәләтеннән һәм мөлкәтеннән файдалана. Икътисадый эшчәнлек хокукына эшкуарлык эшчәнлеген башкару һәм алып бару мөмкинлеген тәэмин итә торган конкрет хокуклар керә.

Шулай ук Конституциядә беркетелгән хосусый милек хокукы, демократик базар икътисадының аерылгысыз шарты буларак социаль-икътисадый мөнәсәбәтләрнең мөһим институты булып тора.

Татарстан Республикасында һәркемгә иҗатның әдәби, сәнгати, фәнни, техник һәм башка төрләре, укыту иреге, аның мәдәни тормышта һәм мәдәният учреждениеләреннән файдалануда катнашуы гарантияләнә (57 статья). Хокукның бу төре кешегә мәдәни ихтыяҗларын гамәлгә ашырырга, аның культурасын үстерергә һәм шулар нигезендә үзенең шәхси һәм сәяси хокукларыннан тулысынча файдаланырга мөмкинлек бирә. Кешенең әлеге хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруы социаль демократик дәүләттән иҗатка ирек гарантиясен; интеллектуаль һәм сәнгать мирасын яклауга хокукын; татар халкының мәдәниятен саклау һәм үстерү, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче башка халык

вәкилләренең милли мәдәниятләрен саклау һәм үстерү хокукын гарантияләүне күздә тота.

Кеше һәм гражданның хокукый статусы анның хокуклары һәм ирекләре белән генә түгел, бурычлары белән дә тасвирлана. Әлеге бурычлар кеше субъект булып тора торган мөнәсәбәтләр даирәсенә кагыла. Татарстан Республикасы Конституциясенең 22 статьясы нигезендә Россия Федерациясе гражданнары Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары нигезендә барлык хокукларга һәм ирекләргә ия һәм бертигез бурычлы. Татарстан Республикасы Конституциясе берничә төп бурычны беркетә. Мәсәлән, Татарстан Республикасында һәркем Татарстан Республикасы Конституциясен һәм Татарстан Республикасы законнарын, Россия Федерациясе Конституциясен һәм федераль законнарны үтәргә тиеш (60 статья). Һәркем законда билгеләнгән күләмнәрдә һәм тәртиптә салымнар һәм җыемнар түләргә тиеш. (61 статья). Ләкин яңа салымнар билгели торган яисә салым түләүчеләрнең хәлен начарайта торган законнар кире көчкә ия булмый. Һәркем табигатьне һәм әйләнә-тирә мохитне сакларга, табигый байлыкларга сакчыл мөнәсәбәттә булырга тиеш. (62 статья). Татарстан Республикасы Конституциясенең 63 статьясында Татарстан Республикасында гражданнар федераль закон нигезендә хәрби хезмәт үтәргә тиеш дип билгеләнә. Моннан тыш, альтернатив граждан хезмәтен узу мөмкинлеге каралган. Татарстан Республикасы Конституциясе белән билгеләнгән бурычлар арасында шулай ук һәркем тарихи һәм мәдәни мирасны саклау турында кайгыртырга, тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне сакларга бурычлы (57 статья).

Татарстан Республикасы Конституциясе республиканың административ-территориаль төзелешен билгели, ул Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләре системасын тәшкил итә торган территориаль оешманы аңлата. Аерым алганда, Татарстан Республикасы Конституциясенең 67 статьясында Татарстан Республикасы территориясе республиканың административ-территориаль берәмлекләре буларак районнарны һәм республика әһәмиятендәге шәһәрләрне үз эченә ала. Республика әһәмиятендәге шәһәр территориясе районнардан торырга мөмкин. Хәзерге вакытта республикада 43 район һәм 14 республика әһәмиятендәге шәһәр исәпләнелә.

Республика Конституциясенең IV кисәге дәүләт хакимиятен оештыру мәсьәләләрен җайга сала. Россия Федерациясе Конституциясенең 11 статьясындагы 2 өлеше нигезендә федерация субъектларында дәүләт хакимиятен алар төзи торган дәүләт хакимияте органнары гамәлгә ашыра. Татарстан Республикасы Конституциясендә Россия Федерациясе Конституциясендәгечә Татарстан

Республикасы дәүләт хакимияте закон чыгару, башкарма һәм суд хакимиятләренә бүленүне күздә тота. Татарстан Республикасы Конституциясенең 9 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Татарстан Республикасында дәүләт хакимиятен Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы судлары гамәлгә ашыра.

Республика Төп Законының IV кисәгендәге 1 бүлек Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрен җайга салуга багышлана. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы – Татарстан Республикасы парламенты – Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең даими эшләүче иң югары вәкиллекле, закон чыгару органы.

Республика Конституциясендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының саны (100 депутат), Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтләр чоры (5 ел), депутат эшчәнлеген гамәлгә ашыру рәвешләре (төп эшчәнлектән аерылмыйча һәм профессиональ даими нигездә), Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эш рәвеше (сессия), республиканың закон чыгару органы вәкаләтләре исемлеге (75 статья), закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектлар исемлеге (76 статья) һәм башкалар карала.

Татарстан Республикасы Президенты статусы дәүләт һәм иң югары вазыйфаи зат буларак Татарстан Республикасы Конституциясенең IV кисәгендәге 2 бүлегендә билгеләнгән. Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауның, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары, шулай ук Татарстан Республикасының халыкара килешүләре, «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсе һәм Татарстан Республикасы белән Россия Федерациясе субъектлары шартнамәләре үтәлешенең гаранты булып тора.

Конституциядә Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидатларга карата таләпләр (30 яшьтән яшьрәк булмаган, Татарстан Республикасы дәүләт телләрен белгән); республика Президентының вәкаләтләр чоры (5 ел); (бер үк зат Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына ике сроктан артыкка сайлана алмый); республика Президентының вәкаләтләр исемлеге (94 статья); шулай ук Татарстан Республикасы Президентының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату очраклары (97 статья) билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт органнары системасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты мөһим урын алып тора. Төп Законның 99 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте – Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма һәм күрсәтмә бирү органы. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Президенты алдында җаваплы, шулай ук аерым мәсьәләләр буенча үз эше турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы алдында хисап тота.

Конституциянең IV кисәгендәге 3 бүлегендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составы (100 статья), шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының вәкаләтләр исемлеге (102 статья) билгеләнә.

Татарстан Республикасы Конституциясенең IV кисәгендәге 4 бүлеге суд хакимияте һәм прокуратурасы органнары эшчәнлегендәге мәсьәләләрне җайга салуга багышлана.

Конституциядә хөкем итү бары тик суд белән генә гамәлгә ашырыла дип белдерелә. Татарстан Республикасында суд хакимиятен Татарстан Республикасы Конституция суды, гомуми юрисдикциядәге федераль судлар, Татарстан Республикасы Арбитраж суды һәм җәмәгать судьялары гамәлгә ашыра. Татарстан Республикасы Конституциясе Татарстан Республикасы Конституция суды эшчәнлеге мәсьәләләрен җайга сала. Аерым алганда, республика Конституция суды судьялары вазыйфасына кандидатларга карата таләпләр (25 яшьтән яшьрәк булмау, югары юридик белем булу һәм юридик һөнәр буенча кимендә биш ел эш стажына ия булу); Конституция суды составы (6 судьядан тора); судьяларны сайлау тәртибе (Конституция суды судьялыгына кандидатларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тигез санда Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тәкъдим итә); республика Конституция суды вәкаләтләре (109 статья) билгеләнә.

Татарстан Республикасы Конституциясендә җирле үзидарә турында аерым бүлек бар. Җирле үзидарә түбәндәге конституциячел принципларга һәм нигезләмәләргә корыла:

- җирле үзидарә үз вәкаләтләре чикләрендә мөстәкыйль була;

- җирле үзидарә органнары дәүләт хакимияте органнары системасына керми;

- җирле үзидарә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне халыкның мөстәкыйль хәл итүен, муниципаль милекне биләү, аннан файдалану, аның белән эш итү тәртибен тәэмин итә;

- җирле үзидарә гражданнар тарафыннан референдум, сайлаулар, турыдан-туры ихтыяр белдерүнең башка рәвешләре һәм башкалар аша гамәлгә ашырыла.

VI кисәк Татарстан Республикасы дәүләт символлары һәм аның башкаласы турында. Аерым алганда, 121 статьяда Татарстан Республикасының Дәүләт гербы, Дәүләт флагы һәм Дәүләт гимны – Татарстан Республикасы суверенитетын, Татарстан халкының үзенчәлеген һәм традицияләрен чагылдыручы рәсми символлары бар дип билгеләнә.

Татарстан Республикасы Конституциясенең VII кисәге Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итү һәм аңа үзгәрешләр, өстәмәләр кертү тәртибен җайга сала. Әлеге кисәктә Татарстан Республикасы Конституциясенең 1 статьясы нигезләмәләре (Татарстан Республикасы характеристикасы, Татарстан Республикасы статусын һәм Татарстан Республикасы территориясе чикләрен үзгәртү мәсьәләләре) һәм 123 статьясы бары тик Татарстан Республикасы референдумы нәтиҗәләре буенча гына үзгәртелү турындагы нормалар булу белән үзенчәлекле. Конституциянең 124 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы закон, әгәр алар өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесенең күпчелеге тавыш бирсә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителгән дип санала.

Йомгаклап үткәндә шуны билгеләп әйтергә кирәк, дөньяда бөтен илләрне һәм халыкларны канәгатьләндерә торган идеаль конституция моделе юк. Һәр дәүләт үз традицияләреннән, реаль сәяси һәм икътисадый вәзгыятьтән чыгып эш итә. Конституциянең эчтәлеге хәзерге рәвешендә республика халкының төрле катламнары мәнфәгатьләрен чагылдыра. Татарстан Республикасы Конституциясе республикада законнар һәм барлык хокукый система үсеше өчен, федераль органнар тарафыннан кайбер искәрмәләр булуга карамастан, кирәкле һәм җитәрлек нигез булып тора. Гамәлдәге Конституцияне сакларга һәм аның хокукый векторын үстерергә кирәк. Конституциячел дәүләт принцибы – Конституция буенча яшәргә өйрәнү, тиешле хокукый рәвешләр ярдәмендә каршылыкларны бетерү.

Тарихи күзлектән караганда, нәкъ менә Конституциядә хокукый нигез салынган, ул республиканың сәяси, икътисадый һәм социаль бөтенлеген тәэмин итә. Нәкъ менә Конституция төп юридик кыйммәтләрнең системага салынган юридик чагылышы булып тора. Барыннан да элек бу – хокук өстенлеге, кешенең тотрыклы хокуклары һәм ирекләре, демократик, хокукый, социаль һәм дөньяви дәүләт булу.